УДК 811.512.145'373

***Р.Ф. Мирхәев***

# ТАТАР ЛИНГВОКУЛЬТУРАСЫНДА «АЛЛА» КОНЦЕПТЫ

Религиозное мировоззрение татарского народа представляет собой особую систему духовных ценностей и традиций, представлений о мире, которая складывалась в течение многих веков под воздействием ислама. В то же время в ней прослеживается и слияние тэнгрианства, которое до принятия ислама исповедовали предки современных татар. Все это определило сложность и многогранность татарской религиозной концептосферы. В качестве ее основополагающего ядра выступает концепт «Алла» – «Бог», в тесной взаимосвязи с которым раскрывается содержание других элементов. Статья посвящена изучению особенностей его вербализации в татарской лингвокультуре. Исследование проведено на основе материала, извлеченного из старотатарских письменных текстов.

**Ключевые слова:** языковая картина мира, религиозное мировоззрение, религиозная концептосфера, религиозный концепт.

Татар халкының дөньяны дини күзаллау системасын күп гасырлар дәвамында формалашкан рухи кыйммәтләр, гореф-гадәтләр һәм карашлар тәшкил итә. Тарихи планда ул мөселман традициясенең йогынтысы астында оеша. Шул ук вакытта анда ислам дине кабул ителгәнгә кадәр хәзерге татарларның борынгы бабалары тоткан тәңречелекнең эзләре дә сакланган. Боларның барысы да безнең көннәргә кадәр килеп җиткән күпсанлы язма чыганакларда чагылыш таба. Бүгенге көндә аларның тел үзенчәлекләрен (график, фонетик, морфологик, лексик) өйрәнеп, күпсанлы фәнни хезмәтләр язылды. Шул ук вакытта күпчелек язма текстларның аерылгысыз өлешен тәшкил иткән, үзендә татар халкының дөньяны күзаллавы һәм аның телдә чагылышы белән бәйле мәгълүматны туплаган дини лексика игътибардан читтә кала бирә.

Фәнни хезмәтләрдән күренгәнчә, әлеге төр лексика галимнәр тарафыннан, әдәби әсәрләр теленең башка үзенчәлекләре белән бергә, лингвостилистик планда, яисә татар әдәби теле нормаларының формалашу һәм үсү тарихы контекстында карала [Ахметгалеева, с. 105–106; Зайнуллин, с. 80–91; Кадирова, с. 120–121; Нуриева, с. 82–83, 137–138; Хаков, б. 71, 117; Хисамова, б. 105, 125, 172, 196, 206, 300]. Бу өлкәдәге тикшеренүләр арасында махсус дини лексикага багышланганнары да бар. Мәсәлән, И.Б. Бәширова XVIII гасыр татар поэзиясе әсәрләре телен өйрәнеп, Аллаһы Тәгалә атамаларының семантикасын ачыклый һәм аларның әдәбистилистик кулланылыш үзенчәлекләрен билгели [Бәширова, б. 124–133].

Татар халкының дөньяны дини күзаллау системасы структур яктан күпкырлы һәм катлаулы күренеш тәшкил итә. Ул үз эченә, «Пәйгамбәр», «Фәрештә», «Оҗмах», «Тәмуг», «Гөнаһ»

концептлары белән бергә, «Кеше», «Язмыш» кебек турыдан-туры бу өлкәгә карамаган һәм билгеле бер контекстта гына өстәмә мәгънә төсмерләренә ия булган берәмлекләрне дә ала. Әлеге системаның үзәгендә аларның барысын үзара бәйләп торучы «Алла» концепты тора.

Ислам динендә Алла үзенә тиңе булмаган, югары акыл, чиксез куәт, тулы камиллек һ.б. сыйфатларга ия изге зат, абсолют башлангыч буларак күзаллана. Татар лингвокультурасында аның вербаль чаралары буларак *Аллаһы Тәгалә / Аллаһы / Алла, Ходай / Хода, Тәңре* лексемалары кулланыла. Килеп чыгышы ягыннан төрле тел берәмлекләре (гарәп, фарсы, төрки-татар) булуларына карамастан, алар барысы да ‘алла, илаһи өстен көч’ мәгънәсен белдерәләр [Татар теленең аңлатмалы..., I т., 2015, б. 137; Татар теленең аңлатмалы ..., I т., 1977, б. 47; Татар теленең аңлатмалы..., III т., 1981, б. 240, 370; Татар теленең этимологик..., I т., б. 93; Татар теленең этимологик ..., II т., б. 245–246, 390].

Хәзерге татар телендә бу лексемалар өчен уртак сүз кулланылышы да хас. Мәсәлән: Алла (Тәңре, Ходай) хөкеме; Алла (Тәңре, Ходай) йорты; Аллага (Тәңрегә, Ходайга) ышанмаучы; Аллага (Тәңрегә, Ходайга) ышанучы; Алладан (Тәңредән, Ходайдан) куркучы; Алла (Тәңре, Ходай) колы; Алла (Тәңре, Ходай) белә; Алла (Тәңре, Ходай) боерса; Алла (Тәңре, Ходай) каргаган; Алла (Тәңре, Ходай) каршына (хозурына, янына) бару; Алла (Тәңре, Ходай) кодрәте белән; Алла (Тәңре, Ходай) ризалыгы өчен; Алла (Тәңре, Ходай) сакласын һ.б.

Әлеге сүзләрнең мәгънә уртаклыгы, сөйләм барышында бер-берсен алыштырып килә алулары иске татар язма чыганакларында да күзәтелә. Биредә алар, Аллаһы Тәгаләне атау белән бергә, билгеле бер контекстта аңа хас булган сыйфатларны да белдереп киләләр. Мәсәлән:

кичерүче: Аллаһыдан ғисмәтнәҗат умар имди [Кол Гали, б. 166];

саклаучы: Мәғаз Аллаһ, ул иш рәуа ирмәз имди [Кол Гали, б. 166];

әмер бирүче: Аллаһ әмрин сындурмаға қурқарвән [Кол Гали, б. 236] һ.б.

бар нәрсәне белүче: Хода йа, бу хаҗәтем сәңа мәғлүм [Кол Гали, б. 104];

коткаручы: Ходавәндә, фазлең берлә қуртар имди! [Кол Гали, б. 104];

язмышларны билгеләүче: Ходавәндә, ходавәндә, сәнең хөкемең кәлтүрде бәни бунда [Кол Гали, б. 158];

хөкем итүче: Қыйамәт булса, Хода булыр үзе қази [Мөхәммәдъяр, б. 55] һ.б.

Моннан тыш Аллаһы Тәгаләнең табигате, аңа хас булган сыйфатлар язма текстларда контекст ярдәмендә дә ачыла: Қөдрәтең вар, «Ул!» дидекең улур имди [Кол Гали, б. 48]; Андан соңра шиддәтләрдән бән қортарам, атасына хәқиқәтдә бән күстәрәм, дәүләтин вә мөлкәтин бән артдырам, таҗ вә тәхет, солтанат вирәм имди [Кол Гали, б. 78]; Сонғы берлә байық бәни ул йаратды,

буның кеби күрекле җәмаль ул дүзәтде, бу қазаны үстүмә ул йөретде, аның хөкемен һич кемсәнә йықмаз имди [Кол Гали, б. 126].

Алда әйтеп үтелгәнчә, татар телендә Алланың атамасы буларак төрки-татар асыллы *Тәңре* сүзе дә кулланыла. Борынгы төрки телдә ул баш Күк Алласын белдергән [Древнетюркский словарь, с. 544; Сравнительно-историческая..., с. 562–564]. Ислам дине кабул ителгәннән соң, әлеге сүзнең семантикасы мөселман традициясенә хас булган өстәмә мәгънәләр белән баеый. Шуның нәтиҗәсендә ул алга таба да кулланылыштан төшеп калмый. Билгеле бер контекстта аның ярдәмендә Аллаһы Тәгаләнең түбәндәге сыйфатлары ачылырга мөмкин:

куркуга салучы: Йағқуб сәүчи хақға ғаси һич улмады, сезләр дағы Тәңредән курқың имди! [Кол Гали, б. 70];

чиксез кодрәт иясе: Бу хәлдә Тәңредән фәрман улды, қөдрәт берлә күкдә қара булут туғды [Кол Гали, б. 106]; Әйа Зөләйхә, күрдүңмү, қадир Тәңремнең қодрәтенә ирдүңмү [Кол Гали, б. 172];

язмышлар белән идарә итүче: Бу тәқдири Тәңредән белмеш кәрәк [Кол Гали, б. 100]; Бу тәқдир Тәңремдәндер, белең мәғлүм [Кол Гали, б. 102];

җәза бирүче: Бәңа бу қазаны Тәңре вирди [Кол Гали, б. 86]; Сәңа бу қазаны Тәңре вирди [Кол Гали, б. 94];

мәрхәмәтле, рәхимле, шәфкатьле: Фазле берлә қылсун бәңа Тәңрем рәхмәт [Кол Гали, б. 102]; Һәмандәм Тәңредән мәдәд ирди ‘В тот же миг его достигла милость Бога’ [Кол Гали, б. 116]; Сәҗдә қылыб, Тәңресенә йалварыр имди [Кол Гали, б. 182]; Бән Тәңредән хуб умармын [Кол Гали, б. 256];

кабул кылучы: Доғасыны Тәңреси қабул қылды [Кол Гали, б. 106]; Улуқ сағәт Йусеф сәүчи доға қылди, Тәңредән иҗабәт хасил улды [Кол Гали, б.150];

бер һәм бердәм: Қамулары ушбу сүзә инандылар, җөмләси бер Тәңрейә бүгүлдиләр [Кол Гали, б. 110]; Қодес бике аны күреб, әхуаль белди, Тәңренең берлекинә мөқир қылды [Кол Гали, б. 112];

бүләк итүче: Ул ниғмәтләр бу Тәңремдән [Кол Гали, б. 182]; Тәңре буйруқы улды, ун ики уғыл бәңа рузи қылды [Кол Гали, б. 246];

ярлыкаучы: Йарлықамақ – Тәңредин, һичкем дәгүл [Мөхәммәдьяр, б. 54].

Язма текстларда Алланың төрки-татар асыллы икенче атамасы буларак *Изе* сүзе дә очрый (< *Ädi // Äzi* ‘алла, хуҗа’): Изем бәңа рузи қылды бу дәүләти [Кол Гали, б. 120]; Изеси қаза вирмеш [Кол Гали, б.196].

Тәңредән аермалы буларак, биредә ул, нигездә, гарәп асыллы эпитетлар белән бергә кулланыла. Мәсәлән: Хатеримни рәушан қылғыл, Изем лятиф [Кол Гали, б. 48]; Сезгә ғәзим афәт вирә Изем бари [Кол Гали, б. 84]; Әйа солтан, қавидер, қадир ирүр Изем сөбхан [Кол Гали, б. 172]; Улуқ сәғәт ғәреш Изесе, улу Сөбхан, ... [Кол Гали, б. 182]; Аның Изесе вар ирүр, қадир Сөбхан, ... [Кол Гали, б. 196]; Дүгәл

ишә қадир дурур Изем бари [Кол Гали, б. 274]; Қәрдәшләриме дуст қылды Изем сөбхан [Кол Гали, б. 274]; Изең һәм мәзһәбен белмәз татар сән [Мөхәммәдъяр, б. 52].

Гарәп асыллы *гәреш* 'күк түбәсе, күкнең иң югары катлавы'лексемасы белән бергә килгәндә, ул үзенең беренчел мәгънәсендә кулланыла: Ғәреш Изесе безләрә қәһәр қылды [Кол Гали, б. 106]; Аны йаулақ ғәни итмеш Ғәреш Изесе [Кол Гали, б. 128]; Ғәреш Изесе сәңа рузи қылмыш имди [Кол Гали, б. 162].

Шуның белән бергә язма текстларда Аллаһы Тәгаләнең гарәп асыллы башка эпитетлары да теркәлде:

Әхәд (احد) 'Бер': Әлхәмдү шөкер вә сипас ул Әхәдә [Кол Гали, б. 46]; Мөлкәт эчрә биля шәрик ул Әхәдә [Кол Гали, б. 46];

Самәд (صمد) 'Мәңге бетмәс': Самәд күрәр, күргәнин һич йаңылмаз, Самәд бушуб йаздығын қол аңламаз, Самәд уқы дуқынса, һич уңалмаз [Кол Гали, б. 168]; Йусеф сиддиқ бәнүм қолум улур иди, ғобудийәт Самәдинә қылур ирди, мөдам Самәд әмрилә йүрер ирди, Самәд аңа улу мөлек вирир имди [Кол Гали, б. 212];

Зүл-Җәлял (ذولجلال) 'Олылык иясе': ... аны бақи Зүл-Җәлял белдек имди [Кол Гали, б. 46];

Җәббар (خبار) 'Куәтле': Аның васфын Қөръан эчрә үкди Җәббар [Кол Гали, б. 46]; Иқрар қылдым, инандым бер Җәббарә [Кол Гали, б. 214];

Ғәффар (غفار) 'Кичерүче': Зәһи диққәт ғәта вирмеш аңа Ғәффар [Кол Гали, б. 46]; Өмид уйлә дутарым ул Ғәффарға [Кол Гали, б. 262];

Халиқ (خالق) 'Яратучы, бар кылучы': Җөмләсендән Халиқ рази улсун имди [Кол Гали, б. 48]; Кучылардан бәкләсүн Халиқ сези [Кол Гали, б. 54]; Халиқ ани Йусефә мөшфиқ қылды [Кол Гали, б. 68]; Халиқдан узун ғөмер теләр имди [Кол Гали, б. 72]; Халиқ аңа узун ғөмер рузи қылды [Кол Гали, б. 72];

Хақ (حق) 'Чын': Хақдин рәхмәт даим улсун һәм анлара [Кол Гали, б. 48]; Йағқуб сәүчи Хақға ғаси һич улмады [Кол Гали, б. 70]; Хақ сәлями-дөруди кәлди ирсә [Кол Гали, б. 76]; Хақ хөкменә қоллар рази улмыш кәрәк [Кол Гали, б. 100]; Хақ тәқдире бүйлә иркән, кимсә белмәз [Кол Гали, б. 102]; Нәтәр дошман, Хақ мәңа булса йар [Мөхәммәдьяр, б. 47]. И теләкләр биргүче Хақ, Падишаһ, колларыңа сәндин үңин йуқ пәнаһ [Мөхәммәдьяр, б. 54].

Рәхман (رحمان) 'Мәрхәмәтле': Иляһем рәхманемғә сығынмайынму [Кол Гали, б. 48]; Дәрмандәләр дәстгире Мәлик рәхман [Кол Гали, б. 76]; Андан соңра Рәхман рәхим қылдачидур [Кол Гали, б. 198];

Сөбхан (سبحان) 'Мактаулы': Сөбханемдән мәдәд-йари теләмәйенмү [Кол Гали, б. 48]; Сөбхан сәңа тәлим ихсан қылур имди [Кол Гали, б. 54]; Йусеф һәрдәм йалуарыр Сөбханенә [Кол Гали, б. 176]; Мунчә лөтъф-у кәрәм кәлди Сөбханемдән [Кол Гали, б. 182]; Ғилм-ү хикмәт рузи қылмыш аңа Сөбхан [Кол Гали, б. 196];

Мәүля (مولی'مولا ) 'Хуҗа': Мәүлем, сәңа сығынурмын мән

бер зәғиф [Кол Гали, б. 48]; Өмиддер-кем, Мәүлядән мәдәд ирди [Кол Гали, б. 52]; Бәс, Мәүлүмдән әмер-хөкем үйлә улса [Кол Гали, б. 216]; Мәүля бәңа бу ғинайәт качан кыла? [Кол Гали, б. 256];

Лятиф (لطيف) ‘Сизгер’: Хәтеримне рәушан кылғыл, Изем лятиф [Кол Гали, б. 48];

Җәлил (جليل) ‘Бөек’: Әй, кәрдәшләр, күрмәзмесез ул Җәлили? [Кол Гали, б. 66]; Ушбу эше Җәлил рәуа күрмәз имди [Кол Гали, б. 66]; Уд эчендә сақлады аны Җәлил [Кол Гали, б. 70]; Йа Йусеф, Җәлил әмре бүйлә дорыр [Кол Гали, б. 206]; Мәүля Җәлил Җәбраилә һәм бойурды [Кол Гали, б. 222];

Кәрим (كريم) ‘Юмарт’: Иляһәна, кәрим Хәннан, бичаралар өмиде сән, рәхим Мәннан [Кол Гали, б. 74]; Йа Кәрим, дир, фазлең берлә йарлықағыл [Кол Гали, б. 106]; Кәрим Аллаһ кәлименә әмер қылды [Кол Гали, б. 290];

Хәннан (حنان) ‘Мәрхәмәтле’: Иляһәна, кәрим Хәннан, бичаралар өмиде сән, рәхим Мәннан [Кол Гали, б. 74];

Рәхим (رحيم) ‘Рәхимле’: Йа Рәхим, дир, бәнем хәлем сән белүрсән [Кол Гали, б. 106]; Рәхим Мәүлем рәхмәтенә билен бағлар [Кол Гали, б. 184];

Мәннан (منان) ‘Нигъмәт бирүче’: Иляһәна, кәрим Хәннан, бичаралар өмиде сән, рәхим Мәннан [Кол Гали, б. 74];

Мәлик (ملك) ‘Хөкемдар’: Дәрмандәләр дәстгире Мәлик рәхман [Кол Гали, б. 76]; Улуғ мәнсаб вирде аңа Мәлик сөбхан [Кол Гали, б. 108]; Һәман дәмдә бер фәрештә кәлде хазир, виреб йиде ул Йусефә Мәлик қадир [Кол Гали, б. 166]; Андан соңра үкүш дәгүл, бир қач күндән, ғәзизнең җанын алды Мәлик рәхман [Кол Гали, б. 178];

Қадир (قدير) ‘Кодрәт иясе’: Қадир аңа ғәта қылмыш қати қуввәт [Кол Гали, б. 76]; Қадир Мәүлем тәкдирени кем шашыра? [Кол Гали, б. 92]; Бәс, Қадирдән хөкем-фәрман үйлә улды [Кол Гали, б. 122]; Фазле берлә қортарды Қадир дәййан [Кол Гали, б. 200]; Ғәта қылды Қадир сөбхан [Кол Гали, б. 202]; Қадир улдур – қолға ризықын биргүче [Мөхәммәдъяр, б. 54];

Бари (بارى) ‘Юктан бар кылучы’: Сезгә ғәзим афәт вирә Изем бари [Кол Гали, б. 84]; Дүгәл ишә қадир дурур Изем бари [Кол Гали, б. 274];

Ғафир (غافر) ‘Ярлыкаучы’: Бу тәкдире қылды бәңа Мәүлем ғафир [Кол Гали, б. с. 102];

Раббе (رب) ‘Хуҗа’: Йа Раббе, нидән улды безгә ушбу туфан? [Кол Гали, б. 106]; Йа Раббе, зинданы ихтийар қылдым имди! [Кол Гали, б. 176];

Ғәлим (عليم) ‘Бар нәрсәне белүче’: Йа Ғәлим, дир, һәр хәл эчрә сәңа пәнаһ қылдум имди! [Кол Гали, б. 106];

Ғәфур (غفور) ‘Ярлыкаучы’: Ходавәндә, Ғәфур ғөфран, куртылмаға булумадым һәргиз дәрман [Кол Гали, б. 168];

Қави (قوى) ‘бар нәрсәдән көчле’: Әйа солтан, қавидер, қадир ирүр Изем сөбхан [Кол Гали, б. 172].

Мисаллардан күренгәнчә, язма текстларда Аллаһы Тәгаләнең исемнәре күпчелек очракта парлап кулланылалар. Шул

рәвешле аларга хас образлылык тагын да көчәйтелә һәм аңа карата чиктән тыш буйсынучанлык, ихтирам белдерелә.

**Әдәбият**

*Ахметгалиева Я.С.* Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». М.: Наука, 1979. 191 с.

*Бәширова И.Б.* Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2006, 192 б.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

*Зайнуллин Г.Г.* Татарская богословская литература XVIII – начала XX веков и ее стиле-языковые особенности: дис. в виде науч. докл. … д-ра филол. наук. Казань, 1999. 107 с.

*Кадирова Э.Х.* Поэмы Мухаммедъяра «Тухфа-и мардан» и «Нур-и содур: лексика. Казань: РИЦ: «Дом печати», 2001. 232 с.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 543 б.

*Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. Казань: Казанский государственный университет, 2004. 376 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка / отв. ред. Э.Р. Тенишев, А.В. Дыбо. М.: Наука, 2006. 908 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 476 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. III т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I т.: А–В. Казан: ТӘҺСИ, 2015. 712 б.

Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. II т. (М–Я). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 567 б.

*Хаков В.Х.* Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.

*Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии (XVI – нач. XIX в.). Казань: Мастер Лайн, 1999. 408 с.

*Мәкалә РФФИ һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 16-14-16011 номерлы проект кысаларында әзерләнде*

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*